# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

422000, Татарстан Республикасы, Арча ш., Совет мәйданы, 14
телефон:(84366) 3-00-33,факс: 3-14-33, e-mail: 16T.009@tatar.ru

# К А Р А Р

14.03.2016

№ 16

**2016 елның 13 мартында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе **2016 елның 13 мартында** узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

"2016 елда Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлардан 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - торак пунктларга янгын гидрантлары сатып алу;<br>Яңа Кишет авылы | 15 000 |
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | юлларны ремонтлау (вак таш, торбалар сатып алу).<br>Яңа Кишет авыл җирлеге территориясенә кергән барлык авылларда | 126 000 |
| 3 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | - Яңа Кишет авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда урам яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру;<br>-Чишмәләр төзекләндерү | 8 000<br>12 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | Кшкар авылына скважиналар өчен насос алу | 7 000 |
| | | Барлыгы: | 168 000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 937 референдумда катнашучы кертелгән;

референдумда катнашучылар саны 890, бу 94,98 процент тәшкил итә;

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 788 кеше тавыш бирде, бу 88,54 процент тәшкил итә;

«юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 102 кеше тавыш бирде, бу 11,46 процент тәшкил итә.

Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча районы Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган дип танырга, ә референдум нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:

"2016 елда Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлардан 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - торак пунктларга янгын гидрантлары сатып алу;<br>Яңа Кишет авылы | 15 000 |
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | юлларны ремонтлау (вак таш, торбалар сатып алу).<br>Яңа Кишет авыл җирлеге территориясенә кергән барлык авылларда | 126 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | - Яңа Кишет авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда урам яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру;<br>-Чишмәләр төзекләндерү | 8 000<br><br><br><br><br>12 000 |
| 4 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | Кшкар авылына скважиналар өчен насос алу | 7 000 |
| | | Барлыгы: | 168 000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

3. Җирле референдумның гомуми нәтиҗәләрен Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе — Б.И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре — Л.И. Нурмиева